ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 июня 2024 г. № 3755

Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5184 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1004 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«күпфатирлы йорттагы бүлмәне яңадан планлаштыру мондый бүлмәнең чикләрен һәм (яки) мәйданын үзгәртүдән, һәм (яки) яңа бүлмәләр барлыкка килүдән, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яки) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән гыйбарәт (шул исәптән бүлмәнең чикләрен һәм (яки) мәйданын үзгәртмичә). Шулай ук, бүлмәне яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә янәшә бүлмәләрнең чикләре һәм (яки) мәйданы үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бүлмәнең (бүлмәләрнең) чикләре һәм (яки) мәйданы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры мәгълүматларына үзгәрешләр кертү яки барлыкка килгән бүлмәләрнең дәүләт кадастр исәбен һәм барлыкка килгән бүлмәләргә хокукны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру зарурлыгына китерә;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов